**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

| **«Раслыйм»** | **«Килешенде»** | **«Килешенде»** |
| --- | --- | --- |
| Директор<br>_________Шәрәфетдинов Р.Г.<br><br>Боерык №<br>«  28  » август 2014 нче ел | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары<br>___________Козлова Н.В.<br><br>«__28__» август 2014 нче ел | Методик берләшмә житәкчесе<br>________Шәрәфетдинова Г.Ф<br><br>Беркетмә № __1_<br>«_25___» август 2014 нче ел |

**6 нчы “А” сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан эш программасы**
**(рус төркеме)**
Төзүче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрәфетдинова Гүзәл Фәсхетдин кызы

Педогогик киңәшмә
утырышында каралды.
Боерык № 1

2014-2015 нче уку елы

**Татар әдәбиятыннан эш программасы**

**6 нчы сыйныф**

**(70 сәг)**

**Аңлатма язуы**

***Эш программасы статусы.***

Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:
Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации))

2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы.

- 6 статья – белем алу теле (телләре)

- 7 статья – мәгарифнең дәүләт стандартлары

-10 статья –уку-укыту программалары

- 32 статья – мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы.

3. . “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (№794 от 25.10.2013)

4.Татар теленнән гомуми белем бирү стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. Казан , 2008ел.

5. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)” 1-11 нче сыйныфлар, К.С.Фәтхуллова, Ф.Х.Җәүһәрова, Казан, “ Мәгариф” нәшрияты, 2010ел.

6.Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1-11 нче сыйныфлар)/ Төзүчеләре: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. – Казан: Тат.кит. нәшрияты, 2011.ел

7. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.(Методик тәкъдимнәр)

8. Дәреслек: Р.З.Хәйдәрова, З.Р.Нәҗипова “Татар теле.” 6нчы сыйныф. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010ел

9. МБГБУ “Иске Мукшы урта гомуми белем мәктәбе”нең уку планы. (Уку планы буенча боерык №179 1 нче сентябрь 2014 нче ел).

***Эш программасы структурасы***.

Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***

***Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбияты укытуның төп максаты һәм бурычлары.***

1992 нче елның 8 нче июлендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Законы нигезендә татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып расланды һәм Татарстан Республикасы мәктәпләрендә рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен дәүләт теле буларак укыту процессы башланды. Мәгариф министры җитәкчелегендә бик кыска вакыт эчендә бу өлкәдә нәтиҗәле эш оештырылды: махсус программалар, дәреслекләр, методик әсбаплар, дидактик материаллар әзерләнде, “Татарстан мәктәпләрендә татар телен дәүләт теле буларак укыту эчтәлегенә таләпләр минимумы” төзелде.

Моңа кадәр рус телендә сөйләшүче балалар татар теленең грамматик нигезләрен үзләштерү дәвамында аерым күнегүләр эшләргә, диалог һәм монологлар төзергә генә өйрәнеп килделәр. Әмма сүз сәнгатенең асыл нигезен тәшкил иткән әдәби әсәр игътибардан читтә кала килде.

Сәнгатьнең бер төре булган әдәбият белән танышу әдәби уку дәресләрендә башлана. 5-9 нчы сыйныфларда эстетик әһәмияткә ия булган күләмлерәк әсәрләрне әдәбият дәресләрендә укуны дәвам итәбез.

Рус телендә сөйләшүче балалар өчен әдәби уку дәресләре татар язучыларының иң матур әсәрләре белән танышу, аларны дөрес интонация белән, басымнарны урынлы куеп уку, аңлау, истә калдыру, аерым гыйбарәләрне, сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне сөйләмгә кертеп җибәрүгә юнәлдерелергә тиеш. Әдәби текст баланы матур җөмләләр төзеп сөйләргә, татарча аралашуга этәрергә тиеш.

**Тәкъдим ителә торган программаның максаты:**

- башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, алар гомумкешелек әхлакый сыйфатларын тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның татар телен өйрәнүгә кызыксынуларын, ягъни уку мотивациясен көчәйтү;
- рус телендә сөйләшүче балаларны татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләр белән таныштыру;
- татар халкының тарихына, мәдәниятына ихтирам хисе тәрбияләү;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү аша, укучыларның татар телендә телдән һәм язмача аралашу мөмкинлекләрен киңәйтү;

әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычлар куела:

- мәктәп баласының сөйләү, уку, тыңлау сәләтен үстерү, төрле текстларны өйрәтүнең нигезләрен аңлату;
- баланы мөстәкыйль рәвештә китап укырга әзерләү;
- татар әдәбиятына, сәнгатенә, мәдәниятенә кызыксыну һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү;
- татар әдәби текстларын дөрес интонация белән укырга өйрәтеп, сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру;
- тексттагы сүзләрдән, гыйбарәләрдән файдаланып, эчтәлек сөйләргә өйрәтү;
- татар телендә язылган әдәби әсәрнең моңын, аһәңен тоярга өйрәтү.

Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, анда иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда эстетик принцип (укучыларның матурлыкны күрә алуы һәм башкаларны күрергә өйрәтә алуы), эзлеклелек (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), психологик принцип (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, белем дәрәҗәләрен исәпкә алып эш итү); аерым алып карауны таләп итә торган принцип итеп коммуникативлык принцибы килеп керә, чөнки әдәбият дәресләрендә алынган белем балаларның аралашу чарасына әверелергә тиеш. Укучыларны әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, дифференциацияләү дә (аерым төркемнәргә бүленеп эшләү) һәм интеграцияләү (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алган белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) үзәккә алына.

Рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләгән вакытта өстенлек иҗади уку (сәнгатьле уку), репродуктив методларга бирелә. Балаларның үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен эзләнү методы алына. Биредә метод һәм алымнарны төрләндерүгә, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, аларның әдәби үсеш үзенчәлекләренә таяну, башка әдәбиятны кабул итү шартлары, укучыга җиткереләчәк материалның күләме, әлеге курсны үзләштерүнең максаты һәм бурычлары да йогынты ясаячак.

Төрле сәнгать вәкилләре белән таныштыру, алар турында укучыларның татарча сөйли белү күнекмәләренә ирешү – программа бурычларының берсе.

Билгеле булганча, рус телендә сөйләшүче балаларга татар телендә укыту максатларының берсе – аларны язма сөйләм аша аралашырга өйрәтү. Шуңа күрә уку һәм татар әдәбияты дәресләрендә төрле характердагы язма эшләр эшләү дә максатка ярашлы эш төре булып тора. Аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:

- әсәрнең планын төзү;
- әсәр геройлары турында үз фикереңне язу;
- әсәрнең сюжетын үзгәртеп, яңа хикәя төзү;
- күргән, ишеткән турында хикәяләп язу, һ.б.;
- укылган әсәрнең эчтәлеге буенча инша язу;
- бирелгән темага өйрәнелгән әдәби әсәр буенча сочинениеләр язу.

Гомүмән алганда, рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбиятын оригиналда укыта башлау татар телен өйрәнүнең дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәбият хәзинәләребезне башка халыклар арасында таратуга юл ачачак.

Укыту планында 6 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан тематик планны “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбиятын укыту буенча сынап карау программалары”на (Р.З. Хайдарова, Р.Л. Мавлафеева. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. 2003) нигезләнеп төзедем. Программада 70 сәгать каралган. текст өстендә эш – 56 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 13 сәгать, класстан тыш уку – 1 сәгать

**Эчтәлеге.**

| № | Төп тема | Сәгать саны | Лексика | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Яңа уку елы котлы булсын | 7 | Киңәшче,фән, уй, сердәшче, олы, кече, сеңел, пөхтә, һәрвакыт,мил-ли, басма, тамга, китап басучы,бал –чык, кулъ язма, һәйкәл,аңлатмалы сүзлек, галим,бастыра, төзи, уңай-сыз,теләсә кая, чирек, бөгәрли, зарлана, шагыйрь, онытма, мәңге, хәтер, кайнар, танымый, буяу, чәйни, таш | - Ж. Тәрҗеманов “Якын дус”<br>- Китапка ничә яшь?<br>- Каюм Насыйри – зур галим.<br>- Көндәлек нигә елый?<br>- Гөлшат Зәйнашева иҗаты.“Бер атнада ничә көн?”<br>- Әкият-пьеса “Гатаның хатасы”. |
| 2 | Мин – зур ярдәмче | 11 | Яңа, тәрбияле, минемчә. елмая, әйләнеп кайта, әсирлеккә эләгә, истәлек, очрашу, Бөек Ватан сугышы, бергәләп, көтәм, барыбер, егет, әкрен, ачык, тыйнак, тәвәк –кәл, тәкъдим, | - “Алсу” хикәясе.<br>- А. Алиш “Әни ялга киткәч” хикәясе<br>- Ф. Яруллин. “Әхмәт” хикәясе.<br>- Д. Аппакова “Сөяк саплы пәке” хикәясе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | бал корты, кәрәз, башкача, бәхетле, чишмә, эссе, кызганыч сизә, кое, эшчән, ярдәм- чел, алдакчы, иҗат, аеруча, рәссам, фил, пәке, кесә, сап, шәп, берьюлы курка, кинәт, шома, курка, кинәт, шома, сызгыра, кычкыра, сумса | |
| 3 | Татарстан – мөстәкыйль дәүләт | 12 | Ниһаять, дәүләт, сәясәт, ил, җәм-гыять, шартнамә, күпмилләтле, ышаныч, тантана, идарә итү, ти –гез хокуклы, бурыч, башлык, кала, канәфер горур, җан, борнгы, тарихи, сайлау, тәмамлый | - Англия кунаклары.<br>- Татарстан – мөстәкыйль дәүләт<br>- Мин яратам сине, Татарстан!<br>- М. Ш. Шәймиев - Татарстанның беренче Президенты<br>- Казан – Татарстан башкаласы |
| 4 | Әдәбият – сәнгать дөньясы | 5 | Чыгыш ясый, әсәр, сәхнә, көй, сәләтле, танылган, менү, учак, куну, юлдаш, хөрмәт итү, үлемсез, җыентык, яшерен, әйләнәсендә, әйләнергә, ефәк кушак | - Казан театрлары<br>- Салих Сәйдәшев<br>- “Яшь туристлар” җыры.<br>- Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты. “Суөык бабай” шигыре |
| 5 | Иптәшең үзеңнән яхшы булсын | 6 | Берүзе, сөендем, һәркайсының кызгана, ватарсың, рәхәтләнеп, йөрәге авырту, кан басымы, авызы ерылу, аяклары җиргә тими, аяклары бии башлау, көнбатыш, түбәле капка, чыланган, кызганыч | - “Чын дуслар”хикәясе.<br>- “Яңа чана” хикәясе<br>- “Сашаның дуслары” хикәясе<br>- “Кинога барганда”хикәясе |
| 6 | Туган көн – күңелле бәйрәм | 4 | Белгәннәр, тылсымчы, түләүсез, җыентык, халыкара, лаек була, гадел, кыю, өлеш, сумса, бавырсак, башваткыч, мәзәк | - “Туган көн” җыры<br>- Ш.Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Кунаклар” шигыре |
| 7 | Дүрт аяклы дусларыбыз | 5 | Токым, кыя, фән, гадәт, якын, | - “Юлдаш – авыл эте ” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ялтырый, шатлана, сөяк, кәеф, сөйләшә, иртүк, билләһи, ялганлау, исән-сау, оныk, элемтәче, хәбәр, яралы, юа, үтүкли, беркем | - “Авыл эте Акбай” пьесасы<br>- Бөек Ватан сугышында этләр<br>- “Рәхәт безнең Акбайга” |
| 8 | Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | 6 | Тартма, аерыла алмый, чыныгу, шөгыльләнә, үрнәк, ихтыяр көче, дөнья, чын-чынлап, үрнәк, балыкчы, яр, тал, диңгез, сәяхәт, кыргый хайван, ашыгу, җәяүле, борылыш, ишегалды, бераздан, иснәү | - Сәламәт тәндә-сәламәт акыл<br>- Гата Камский – атаклы шахматчы<br>- “Мин-балыкчы” – шигыре<br>- “Фәндүс, Илдус һәм Фирдүснең урманга сәяхәте” хикәясе<br>- Юл йөрү кагыйдәләре<br>- “Настя” хикәясе<br>- “Олегның эте Бим” хикәясе |
| 9 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 13 | | |
| 10 | Класстан тыш уку | 1 | | |
| | Барлыгы | 70 | | |

***5 – 9 нче сыйныфны тәмамлаган рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерергә тиешле белем –күнекмәләр.***

1. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга өйрәтү.
2. Сәнгатьле укырга әзерлек кагыйдәләрен хәтергә сеңдерү. Эчтәлеккә туры килгән картинаны күз алдына китерү, шигырь яңгырашын ишетә белү.
3. Йөгерек, аңлы, дөрес, сәнгатьле уку. Әдәби тел нормаларын истә тотып, теләсә нинди жанрда язылган әсәрне үзлектән аңлап укый белү.
4. Укылган әсәрләрдән төп фикерне укучының аерып күрсәтә алуы, үз сүзләре белән төп фикерне әйтә белүе, текстның төп фикерен билгеләп, өлешләргә, кисәкләргә аеру.
5. текстны үзлектән төзелгән планга нигезләнеп, иллюстрациягә таянып, кыска һәм төгәл итеп сөйли белү. Аерым темага хикәя төзү өчен материал табу.
6. Әдәби әсәрдәге геройларга бәя бирә белү.
7. тексттагы сүзләрнең мәгънә төсмерләрен аера белү, аларны сөйләмгә кертеп җибәрү. Әсәрдә аларны табу, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләренә игътибар итү, мәгънәләрен аңлап калу.
8. Әсәрдәге вакыйгаларны күпертеп сурәтләнгәндә, геройларның тирә-юньдәге табигатькә мөнәсәбәтен күрсәткшндә автор кулланган сурәтдәү чараларын (чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар, фразеологик әйтелмәләр)  күрә һәм аерып алырга өйрәтү.

9. Иҗади хикәяләр төзү: кайөсы да булса бер герой исеменнән, ягъни затын үзгәртеп сөйләү, геройның язмышы турында хикәяне дәвам итү, тормыштагы вакыйгалар турында хикәя төзү, күзәтү элементларын кертеп, тасвирлауны үзгәртеп сөйләүкүнекмәләрен булдыру.
10. Язучы биографиясен билгеле бер эзлеклелектә сөйөләү күнекмәләрен булдыру.

**Календарь – тематик план**

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дәрес тибы | Коммуникатив максат | Контроль төре | Үзләштерергә яки камилләштерергә тиешле белем һәм күнекмәләр | | Өй эше | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Лексика | Грамматика | | | |
| | | | | | | | | | План | Факт |
| | | | **Яңа уку елы котлы булсын** | | | | | | | |
| 1 | Яңа уку елы белән! | 1 | Бсү | Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра белү, итәгатьле сүзләр -не кабатлау. | | Уку-язу әсбаплары исемнәре. | Эндәшү, исәнләшү сүзләре. | Үзең турында хикәя төзергә | 01.09 | |
| 2 | Җ. Тәрҗеманов “Якын дус” | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Укучыларны шигырьне дөрес, сәнгатьле укырга өйрәтү. | | Киңәшче,фән, Уй, сердәшче | | Шигырьне ятларга | 05.09 | |
| 3 | Минем мәктәбем. | 1 | Бсү | Әңгәмәдәшең-нең яшәү уры -нын, хәлен со-рый һәм үзең турында хәбәр итә белү. | | Олы, кече, се-һел, пөхтә, һәрвакыт | | Мәктәп турында хикәя төзергә | 08.09 | |
| 4 | Китапка ничә яшь? | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Тарихи фактлар-га таянып, китап -ның килеп чы-гышы турында тулы мәгълүмат җыю. | | Милли,басма, тамга, китап басучы,бал – чык, кулъ язма, һәйкәл | | Текстның эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә | 12.09 | |
| 5 | Каюм Насыйри – зур галим. | 1 | Текст өстендә эшләү дәресе | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү, китап | | Аңлатмалы сүзлек, галим, бастыра, төзи | | Текстны сөйләргә өйрәнергә | 15.09 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | һәм башка мәгълүмат чыганаклары белән эшләү. | | | | | | |
| 6 | Көндәлек нигә елый? | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Кире кага һәм раслый белү күнекмәләрен булдыру. | | Уңайсыз,телә -сә кая, чирек, Бөгәрли, зар-лана | Кире кага һәм раслый белү күнек-мәләрен булдыру. | Хикәяне сәнгатьле укырга өйрәнергә | 19.09 | |
| 7 | Гөлшат Зәйнашева иҗаты. “Бер атнада ничә көн?” | 1 | Текст өстендә эшләү дәресе | Атна көннәрен сөйләмдә куллана белү. | | Шагыйрь, онытма, мәңге | | Шигырьне ятларга | 22.09 | |
| 8 | Әкият-пьеса “Гатаның хатасы”. | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Әкиятнең мәгънәви ягын табарга өйрәтү. | | Хәтер Кайнар Танымый Буяу | | Рольләргә бүлеп, сәнгатьле укырга өйрәнергә | 26.09 | |
| 9 | Әкият-пьеса “Гатаның хатасы” (дәвамы) | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Кире кага һәм раслый белү. | | Чәйни Таш | | Әкият-пьесаның эчтәлеген сөйләр-гә өйрәнергә | 29.09 | |
| 10 | “Минем яраткан китабым” хикәя төзү | 1 | Бсү | Өйрәнелгән сүзләрне кулла - нып, хикәя төзи белү күнекмәлә - рен ныгыту. | Хикәя төзү | | | Хикәяне сөйләргә өйрәнергә | 03.10 | |
| | | | **Мин – зур ярдәмче** | | | | | | | |
| 11 | “Алсу” хикәясе. | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Укучыларның фикерләү сәлә-тен үстерү, сүз-лек байлыгын арттыру | | Яңа Тәрбияле Минемчә Елмая | | Хикәяне сәнгатьле укырга өйрәнергә | 06.10 | |
| 12 | Абдулла Алишның тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Текст өстендә эшләү дәресе | Фикерне дөрес һәм төгәл итеп әйтә белү күнек-мәләре булдыру. | | Әйләнеп кайта,әсирлек кә эләгә, истә-лек, очрашу Бөек Ватан | | А.Алишның биографиясен сөйләргә өйрәнергә | 10.10 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | сугышы | | | | |
| 13 | А. Алиш “Әни ялга киткәч” хикәясе. | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Текстны аңлап уку алымнарын өйрәнү. | | Бергәләп, кө-Тәм, барыбер, егет, икәү | | Хикәяне сәнгатьле укырга өйрәнергә | 13.10 | |
| 14 | “Әни ялга киткәч” хикәясен сәхнәләштерү | 1 | Бсү | Укучыларның иҗади сәләтләрен, театраль осталыкларын үстерү.. | | Әкрен, ачык, тыйнак, тәвәк –кәл, тәкъдим | | Үзегез язган пьесаны сәнгатьле укырга өйрәнергә | 17.10 | |
| 15 | А.Алиш “Нечкәбил” әкияте | 1 | Кту | Парлап һәм кол-лективта эшләү күнекмәләрен ныгыту. | | Бал корты, кәрәз, | | Әкиятне сәнгатьле укырга | 20.10 | |
| 16 | А.Алиш иҗатын йомгаклау дәресе. | 1 | Йомгаклау дәресе | Логик фикерләү күнекмәләрен ныгыту. | | Башкача Бәхетле | | А.Алиш иҗаты турында 5 сорау (тест) әзерләп килергә | 24.10 | |
| 17 | Ф. Яруллин. “Әхмәт” хикәясе. | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Хикәянең идея-эчтәлеген ачу күнекмәләрен ныгыту. | | Чишмә, эссе, кызганыч, сизә, кое | | Хикәяне сәнгатьле укырга өйрәнергә | 27.10 | |
| 18 | Әдәби терминнар (герой-ларга характеристика бирү, чагыштыру алымы). | 1 | Бсү | Укучыларны әдәби терминнарны сөйләмнәрендә кулланууга өйрәтү. | | Эшчән, ярдәм -чел, алдакчы | | “Әни ялга киткәч” хикәясендәге ма-лай белән Әхмәтне чагыштыры характерларга | 31.10 | |
| 19 | Дәрҗия Аппакова. Тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Текст өстендә эшләү | Сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | | Иҗат, аеруча, рәссам | Укытучы булып эшли төзелмәсе. | Д. Аппакова биографиясен сөйләргә | 10.11 | |
| 20 | Д. Аппакова “Сөяк сап -лы пәке” хикәясе | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Хикәядә күтәрел -релгән мәсьәлә -ләргә укучылар-ның үз карашын булдыру. | | Фил, пәке, ке-сә, сап, шәп, берьюлы, | | Хикәяне сәнгатьле укырга, эчтәлеген сөйләргә | 14.11 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Беренче хикәя (дәвамы). | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Укучыларның аңлап, йөгерек укуларына ireш | | Курка, кинәт, шома, булыр | | Хикәяне сөйләргә өйрәнергә | 17.11 | |
| 22 | Икенче хикәя (дәвамы) | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Укучыларны текст белән эш-ләү күнекмәлә-рен камилләште | | Карандаш ия-се, курчак | | Хикәяне сөйләргә өйрәнергә | 21.11 | |
| 23 | Өченче хикәя (дәвамы) | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Укучыларны хикәянең план-ын төзергә өйрә-тү һәм план бу -енча әңгәмә | | Сызгыра, кыч –кыра, сумса | | Беренче өлешен сөйләргә өйрәнергә | 24.11 | |
| 24 | Дүртенче хикәя (йомгаклау) | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Укучыларның үз фикерләрен ма-тур һәм ачык итеп әйтә белү-ләренә ирешү. | | Үзгәртү, үке-нү, кичереш, хакым юк, | | Хикәяне сөйләргә | 28.11 | |
| 25 | “Мин – зур ярдәмче” темасын йомгаклау | 1 | Йомгаклау дәресе | Укучыларның иҗади эшли белүләренә ирешү. | 10 мин тест | Өйрәнелгән сүзләрне кабатлау. | | Әтисе сөяк саплы пәкене ни өчен Рөстәмгә бирде? Фикереңне яз | 01.12 | |
| | | | **Татарстан – мөстәкыйль дәүләт** | | | | | | | |
| 26 | “Татарстан” темасы. Англия кунаклары. | 1 | Уку дәресе (аңлатмалы уку) | Текстны анализ -лап укып, мәгъ -лүмат алу бурычын кую. | | Ниһаять, дәү-ләт, сәясәт, җәмгыять, ил | Көтелгән кунак төзелмәсе | Хикәяне сәнгатьле укырга | 05.12 | |
| 27 | “Татарстан – туган җирем” темасына хикәя төзү | 1 | Бсү | Укучыларны ту-ган як турында белгәннәренә тая -нып, хикәя төз-ергә һәм дөрес дәлилли белергә өйрәтү. | | Шартнамә, күпмилләтле, ышаныч, тантана | | Хикәяне сөйләргә өйрәнергә | 08.12 | |
| 28 | Татарстан – мөстәкыйль дәүләт | 1 | Сөйләм телен үстерү дәресе | Күпдәлилле фи -керләү тибын-дагы текстка үз | | Идарә итү, ти –гез хокуклы, бурыч, | Татарстанның гимны төзелмәсе | Чит илдән килгән кунакларга Татарстан турында | 15.12 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | өстәмәләрен кер-теп, әңгәмә үткәрү. | | башлык | | сөләргә әзерләнергә | | |
| 29 | Мин яратам сине, Татарстан! | 1 | | Укучыларның аңлап, йөгерек укуларына ирешү. | | Кала, канәфер горур, җан | | Шигырьне ятларга | 19.12 | |
| 30 | М.Ш.Шәймиев-Татарстанның беренче Президенты | 1 | Сөләм телен үстерү дәре-се (диалог, монолог) | Укучыларның күзаллауларын киңәйтү. | | Тарихи Сайлау Тәмамлый | Район ,авыл атамалары | Текстны сөйләргә | 22.12 | |
| 31 | Казан – Татарстанның башкаласы. | 1 | Уку дәресе | Укучыларның әдәби сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | | Борынгы | Миллоннан артык төзелмәсе | Хикәяне сәнгатьле укырга | 26.12 | |
| 32 | Йомгаклау дәресе (Татарстан – туган җирем) | 1 | Иомгаклау дәресе | Сөйләм күнекмәләрен камилләштерү | | Тема буенча сүзләрне кабатлау | | 106 нчы бит9 нчы күнегү сораулары-на телдән җавап | 12.01 | |
| 33 | Диалоглар уку һәм төзү. | 1 | Бсү | Сорау-җаваплар-ны ситуациягә туры китереп куя белү. | | | | Тема буенча 5 сорау (тест) әзерләп килергә | 16.01 | |
| 34 | Мөстәкыйль эш. Тест. (Татарстан темасы) | 1 | Мөстәкыйль эш дәресе | Татарстан темасын йомгаклау. | Тест | | | “Казан-Татарстан ның башкаласы” – хикәя әзерләргә | 19.01 | |
| | | | **Әдәбият-сәнгать дөньясында.** | | | | | | | |
| 35 | Казан театрлары. | 1 | Текст өстендә эшләү | Казан шәһәрендә -ге театрлар ту - рында мәгълү - мат биреп, уку - чыларны яңа белемнәр белән коралландыру. | | Чыгыш ясый, әсәр, сәхнә, танылган | | Татар академия театры турында сөйләргә әзерләнергә | 23.01 | |
| 36 | Татар композиторлары. Салих Сәйдәшев. | 1 | Текст өстендә эшләү | Дөрес уку күнекмәләрен үстерү | | Сәләтле, көй | | Текстны сөйләргә | 26.01 | |
| 37 | “Яшь туристлар” | 1 | Текст | Җыр текстын | | Менү, учак, | | Җырны ятларга | 30.01 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җыры. | | өстендә эшләү | матур, сәнгатьле укуга ирешү. | | куну, юлдаш, | | | | |
| 38 | Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Текст өстендә эшләү | Фикерләү күнекмәләрен үстерү | | Хөрмәт итү, үлемсез, җы-ентык, яшерен | | Шагыйрь биографиясен сөйләргә өйрәнергә | 02.02 | |
| 39 | “Суык бабай” шигыре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. | | Әйләнәсендә, әйләнергә, ефәк кушак, | | Шигырьне ятларга | 06.02 | |
| 40 | Бәйрәмнәр. | 1 | Бсү | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | | | | 116 нчы биттәге диалогларны ятларга | 09.02 | |
| 41 | Афишалар төзү. “Әдәбият-сәнгать дөньясында” темасын йомгаклау. | 1 | Бсү | Сөйләм телен үстерү. | 10 мин тест | | | Лаеш районыннан чыккан бер сәнгать вәкиле турында сөйләргә | 13.02 | |
| | | | **Иптәшең үзеңнән яхшы булсы** | | | | | | | |
| 42 | Иптәшең үзеңнән яхшы булсын. | 1 | Бсү | Дусларың белән таныштыра белү күнекмәләрен булдыру. | | | Көтелгән кунак төзелмәсе | “Безнең дуслык” дигән темага кечкенә сочинение язарга | 16.02 | |
| 43 | “Чын дуслар”хикәясе. (Кадерле редакция) | 1 | Текст өстендә эшләү дәресе | Укучыларның аңлап укуларына ирешү, күтәрел-гән мәсьәләләргә үз карашын булдыру. | | Берүзе, сөендем | | Хикәяне үзгәртеп төзергә | 20.02 | |
| 44 | “Яңа чана” хикәясе. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Йөгерек укуны камилләштерү. | | Һәркайсының кызгана, ватарсың, рәхәтләнеп | | Хикәяне сөйләргә | 23.02 | |
| 45 | “Сашаның дуслары” хикәясе. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Матур, дөрес итеп уку. | | Йөрәге авыр-ту, кан басы – мы | | Хикәяне укырга | 27.02 | |
| 45 | “Сашаның дуслары” | 1 | Дәрес- | Диалогик-моно- | | | | Хикәяне сөйләргә | 02.03 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хикәясе буенча әңгәмә-дәрес. | | әңгәмә | логик сөйләмне камилләштерү. | | | | | | |
| 47 | “Киногa барганда” хикәясе. | | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Хикәянең төп фикерен табып, бәя бирү ысул -лары формалаш- | | Авызы ерыл-ган, аяклары җиргә тими, аяклары бии башлады | | Хикәяне сәнгатьле укырга | 06.03 | |
| 48 | “Киногa барганда” хикәясе (дәвамы) | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Хикәядәге герой -ның эш-гамәллә -ре аша үз-үзеңә бәя бирә белергә өйрәнү. | | Көнбатыш, түбәле капка, чыланган, кызганыч | | Хикәянең эчтәлеген сөйләргә | 09.03 | |
| 49 | Диалогик-монологик сөйләм. 116 нчы дәрес | 1 | Бсү | Диалогик-монологик сөйләмне камилләштерү. | Контроль | | | “Чын дуслык нин-ди була?” –темасы -на хикәя язарга, узылган текстлар-дан файдаланырга | 13.03 | |
| | | | **Туган көн – күңелле бәйрәм.** | | | | | | | |
| 50 | “Туган көн” җыры. | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Әңгәмәдәшеңне туган көнгә чакыра, туган көн белән котлау күнекмәләрен үстерү. | | Белгәннәр, тылсымчы, түләүсез, | | Җырның сүзләрен ятларга | 16.03 | |
| 51 | Ш.Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Аңлап уку күнекмәләрен булдыру | | Җыкнтык, ха-лыкара, лаек була, гадел, кыю | | Ш.Галиевның биографиясен сөйләргә | 20.03 | |
| 52 | “Кунаклар” шигыре. | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Татар халкының милли ризык-ларының исем-нәрен атап, сөйләмгә кертү. | | Өлеш, сумса, бавырсак, | | Шигырьне ятларга | 03.04 | |
| 53 | Мәзәкләр. Уеннар. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Мәзәкләрнең эчтәлеген аңларга ирешү, | 10 мин тест | Башваткыч Мәзәк | | Мәзәкләрнең берсен сөйләргә | 06.04 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | төркемнәрдә уеннар уйнау. | | | | | | |
| | | | Дүрт аяклы дусларыбыз. | | | | | | | |
| 54 | “Юлдаш – авыл эте” хикәясе. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Укучыларны дөрес, сәнгатьле укырга өйрәтү. | | Токым, кыя фәт, гадәт, койрыгын бол -гый | | Хикәяне сәнгатьле укырга | 10.04 | |
| 55 | “Юлдаш – авыл эте” хикәясе буенча диалог – лар төзү. | 1 | Бсү | Диалогик-монологик сөйләм үстерү. | | Якын, ялты-рый, шатлана, сөяк | | Үзегез төзегзн бер диалогны ятларга | 13.04 | |
| 56 | “Авыл эте Акбай” пьесасы. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Хикәяне роль -ләргә бүлеп, сәнгатьле уку. | | Кәеф, сөйләшә | | Өзекне сәнгатьле укырга | 17.04 | |
| 57 | “Авыл эте Акбай” пьесасы (дәвамы) | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Хикәяне рольләргә бүлеп, аңлап уку. | | Иртүк Билләһи Ялганлау | | Бүлекнең эчтәлеген сөйләргә | 20.04 | |
| 58 | Хат язу күнекмәләрен үстерү. | 1 | Бсү | Сүзләрне тематик берләштерә белү. | | Исән-сау Онык | | Әбигә хат язарга | 24.04 | |
| 59 | Этләр – сугышта! | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Оператив хәтер эшчәнлегенә бәйле сәләтләрне үстерү. | | Элемтәче Хәбәр Яралы | | Этләр турында кызыклы мәгълүмат әзерләргә | 27.04 | |
| 60 | Р. Вәлиева “Рәхәт безнең Акбайга” | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. | | Юа Үтүкли Беркем | | Шигырьне ятларга | 01.05 | |
| 61 | “Авыл эте Акбай” пьесасын сәхнәләштерү. | 1 | Бсү | Театраль осталыкларын, фикерләү сәләтләрен үстерү. | | Тыңлаучан Алга Озата Хәйләкәр | | Песиегез турында сөйләгез | 04.05 | |
| | | | Сәламәт тәндә – сәламәт акыл | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 62 | “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл” 146 нчы дәрес | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Бәйләнешле сөйләм үстерү. | | Тартма, аеры-ла алмый, чыныгу, шөгыльләнә | | Хикәянең эчтәлеген сөйләргә | 08.05 | |
| 63 | Гата Камский – атаклы шахматчы. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Туган якның күренекле шәхесләре белән танышу. | | Үрнәк,ихтыяр көче, дөнья, чын-чынлап, үрнәк | | Гата Камскийй турында сөйләргә өйрәнегез | 11.05 | |
| 64 | “Мин – балыкчы” шигыре | 1 | Сәнгатьле уку дәресе | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. | | Балыкчы, яр, тал, диңгез | | Шигырьне ятларга | 15.05 | |
| 65 | “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл” темасын йомгаклау. | 1 | Бсү | Сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | | Өйрәнелгән сүзләрне кабатлау | | Атаклы спорт мас-терлары турында мәгълүмат тупла | 18.05 | |
| 66 | “Фәндүс, Илдус һәм Фирдүснең урманга сәяхәте” хикәясе. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Лексиканы сөйләмдә активлаштыру | | Сәяхәт, кыр – гый хайван | | Текстны сәнгатьле укырга | 22.05 | |
| 67 | Юл йөрү кагыйдәләре | 1 | Бсү | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү | | Ашыгу, җәяүле, | | Юл йөрү кагыйдәләрен ятларга | 25.05 | |
| 68 | “Настя” хикәясе. | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Юл йөрү кагый-дәләрен аңлаула-рына ирешү. | | Борылыш Төсләр | | Хикәяне сәнгатьле укырга | 29.05 | |
| 69 | “Олегның эте Бим” | 1 | Текст өстен-дә эшләү дәресе | Юл йөрү кагый -дәләрен аңлаула-рына ирешү. | | Ишегалды, бераздан,ис-нәү | | Текстны сөйләргә | 30.05 | |
| 70 | “Кызыл. яшел, сары” юл йөрү кагыйдәләрен үтәү турында сөйләшү Йомгаклау дәресе | 1 | Бсү | Юл йөрү кагый -дәләрен аңлаула-рына ирешү. | | | | “Кызыл. яшел, сары” -хикәя язып килергә | 31.05 | |

**Татар теленнән язма эшләр һәм аларны бәяләү критериясе**
**Сүзлек диктанты күләме**
**Бәяләү**

| Мәктәп тибы<br><br>Билге | Татар һәм рус мәктәпләрендә укучы татар балалары | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Хатасыз | Хатасыз,пөхтә |
| “4” | 1-2 хата | 1-2 хата |
| “3” | 3-4 хата | 3-5 хата,4-5 төзәтү |
| “2” | 5 һәм күбрәк хата | 6 һәм күбрәк хата |

**Контроль диктант күләме**

| Мәктәп тибы<br><br>Сыйныф | Рус мәктәбендә татар балалары | | Рус телле балалар | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел башы | Ахыры | Ел башы | Ахыры |
| I | - | - | - | - |
| II | | | 25 | 30 |
| III | | | 30 | 35 |
| IV | | | 35 | 40 |
| V | 50 | 50-60 | 35-40 | 40-45 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| VI | 55-65 | 60-70 | 45-50 | 50-55 |
| VII | 65-80 | 85-100 | 55-60 | 60-65 |
| VIII | 85-100 | 95-110 | 65-75 | 75-80 |
| IX | 105-120 | 115-125 | 80-90 | 90-100 |
| X | 120-130 | 125-135 | 95-105 | 105-115 |
| XI | 130-140 | 135-140 | 110-120 | 115-125 |

**Бәяләү**

| Мәктәп тибы<br>Билге | Рус мәктәбендә татар балалары | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | 0/0,0/2,1/0 | 0/0,1/0, 0/1 |
| “4” | 2-3/3-2 | 2/2, 3/2, 2/3 |
| “3” | 4/4, 3/6 | 4/4, 3/6 |
| “2” | 6/5, 5/8 | 6/5,5/8 |
| “1” | | |

**Изложение**

**Текстның күләме**

| Мәктәп тибы<br>Сыйныф | Рус мәктәбендә татар балалары | | Рус телле балалар | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел башы | Ахыры | Ел башы | Ахыры |
| V | 70-110 | 110-140 | 55-65 | 65-75 |
| VI | 140-160 | 160-190 | 70-80 | 85-95 |
| VII | 190-230 | 230-270 | 90-95 | 100-100 |
| VIII | 270-310 | 310-350 | 110-120 | 120-130 |
| IX | 350-370 | 370-390 | 130-140 | 140-150 |
| X | 390-410 | 410-430 | 150-160 | 165-175 |
| XI | 430-450 | 450-470 | 175-180 | 190-210 |

**Бәяләү**

| Мәктәп тибы Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион. хата |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысынча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

**Сочинениене бәяләү**

| Мәктәп тибы Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хата. |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысыңча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

**Укыту – методик комплекты**

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбиятын укыту буенча сынап карау программалары” (Р.З. Хайдарова, Р.Л. Мавлафеева. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. 2003)

2. Рус мәктәпләрендәге рус төркеме укучыларына татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты

3. Р.З. Хәйдәрова, Л.Д. Белоусова, Э.Н. Хәбибуллина. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен).

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

| **УМК** | **Укытучы өчен методик әдәбият** |
|---|---|
| **Программа:** Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1-11 нче сыйныфлар.) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан, Татарстан Китап нәшрияты, 2011 ел.<br><br>**Дәреслек:** Р.З.Хәйдәрова, З.Р.Нәҗипова “Татар теле.” 6нчы сыйныф. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010ел | 1Р.Р.Нигъматуллина “Татар теле дәресләрендә рус телле укучылар белән өстәмә эшләр өчен күнегүләр җыентыгы” Яр Чаллы ,2005<br><br>2.Р.Р.Нигъматуллина”Татар телен өйрәнүчеләр өчен кагыйдәләр һәм күнегүләр җыентыгы 1 кисәк” Яр Чаллы, 2005<br><br>3.И.Л.Литвинов “Я начинаю говорить по-татарски” К. 2005 |

**Интернет – ресурслар.**

http://www.mon.gov.ru РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы

http://www.ed.gov.ru Белем бирү буенча федераль агентлык

http://www.fasi.gov.ru Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык

http://www.obrnadzor.gov.ru Рособрнадзор

http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе

http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства

http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге

http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы

http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем полрталы

http://www.mon.tatar.ru http://pedsovet.org Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе

http://www.bytik.ru Мәгариф системасында яңа технологияләр куллану – халыкара конференция

http://www.shoolexpo.ru

http://www. it-n.ru

http://. belem.ru

http://. tatar.ru ТР рәсми серверы

http://. tatcenter.ru ТР мәгълүмати – аналитик порталы

http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы

http://. intertat.ru ТР электрон газетасы

http://. vatantat.ru “Ватаным Татарстан” газетасы

http://. Tatar - kongres.ru Бөтендөнья татар конгрессы

http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте

http://. suzlek.ru on- line русча сүзлек

http://. Abaga.h16.ru “Абага чәчәге” олимпиада

http://. Tugan-tel.at.ru Шрифтлар һәм IT- технологияләр

http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе

http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр

http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар

http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки – татар дөньясы

http://. selet.ru “Сәләт”